Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

№1 (23)

Октябрь, 2017 нче ел

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

Бу санда:

*Гимназия сулышы* 1



*Президент ярышлары* 2-3



*Җәйге истәлекләр* 4



### “АВЫЛ УКЫТУЧЫСЫ” КОНКУРСЫНДА ҖИҢҮЧЕ



«Мәгариф» журналы уздырган “Авыл укытучысы” конкурсы финалында катнашып, гимназиянең башлангыч сыйныфлар укытучысы Ләйсән Габбасовна Мортазина “Белемнең көнкүрештәге чагылышы” номинациясендә җиңү яулады. Конкурсның беренче этабында 500 ләп укытучы катнашса, сайлап алу турын үтеп, финалда 10 укытучы көч сынашты. Укытучылар Казан шәһәренең Ш.Мәрҗәни исемендәге №2 гимназиясендә дәресләр күрсәттеләр. Укытучыларны Мәгариф һәм фән министры Э.Н.Фаттахов котлады.

### “ПРЕЗИДЕНТ ЯРЫШЛАРЫ” БӨТЕНРОССИЯ УЕННАРЫНДА



Ике ел рәттән Мөслим гимназиясе укучылары “Президент ярышлары” Бөтенроссия уеннарында катнашып килә. 5-24 нче сентябрьда Краснодар краеның «Смена» Бөтенроссия балалар үзәге базасында узган быелгы ярышларда Татарстан Республикасыннан ике җиңүче команда - Мөслим гимназиясе һәм Әгерҗенең №2 нче мәктәбе командалары катнашты.

Әзерлек ел дәвамында барды, җәй көннәрендә команда тренер Расыйл Фаттахов җитәкчелегендә шөгыльләнде, ә иҗади конкурска сыйныф җитәкчесе Гөлзирә Ниязовна, Ләйсән Фаилевна, Айсылу Тәлгатовна әзерләделәр. Егет-кызларыбыз илнең барлык төбәкләреннән килгән 86 команда арасында көч сынашты. Баскетбол, футбол, шахмат, дартс, татарча көрәш, сикерү, иҗади конкурс, спорт теориясе буенча ярышлар узды.

*Дәвамы икенче биттә*

# “ПРЕЗИДЕНТ ЯРЫШЛАРЫ” БӨТЕНРОССИЯ УЕННАРЫНДА

***Егет-кызларның үзләре белән сөйләшеп алыйк. Анападан нинди кичерешләр белән кайттылар икән?***

***Кызлар-егетләр, күреп торам: хисләрегез ташый. «Смена» федераль үзәге турында реклама ясарга кушсалар, нинди фразалар кулланыр идегез?***

***Ильгина: «Смена» – сәламәтлек территориясе!***
***Зәлия: «Смена» - дуслар территориясе!***
***Азилә: «Смена» - IT-технологияләр территориясе!***
***Ринат: «Смена» – мавыгулар территориясе!***
***Ләлә: «Смена» – бәйрәмнәр территориясе!***
***Азат: «Смена» – иң шәп ял территориясе!***
***Шамил: «Смена» – күренекле спортсменнар белән аралашу территориясе!***
***Әмир: кыскасы, «Смена» – БЕЗНЕҢ территория!***

***Булды, булды. Рәхмәт. Ә хәзер тәртип белән генә Анапа истәлекләрегез белән газета укучыларны таныштыруыгызны сорыйм.***

**Азилә Кашапова:**

Анапа – Кара диңгез яр буенда урнашкан бик зур шәһәр. Биек таулар арасына сыенып утырган, диңгез бухтасына урнашкан бу шәһәр тарихи истәлекләргә бай. Киноларда гына күреп белгән Анапа маягын шундук танып алдык. Бик күп сугышлар шаһите булган Анапа крепостен күрдек. Россиядә ачык диңгез акваториясенә урнашкан бердәнбер дельфинарий да шунда. Үз гомеремдә беренче тапкыр дельфиннар биюен карадым.



Краснодар краен санатор-курорт зона дип йөртәләр. Монда балалар өчен лагерь һәм санаторийлар бик күп. Ә безнең лагерь Анапа шәһәре янәшәсендәге Сукко бистәсенә урнашкан. Биредә Россия җыелма командаларының 18 төрдәге спорт ярышлары өчен өйрәнү-тренировка мәйданчыклары урнашкан һәм ул «Лучшее место на Юге России для подготовки спортсменов и проведения соревнований» дигән статуска ия булган. “Президент ярышлары” ның һәр ел саен монда үтүе бер дә гаҗәп түгел.

Биредә заманча спорт заллары, ачык һавада тренировка мәйданчыклары, бассейн, бөтен-дөнья стандартларына туры килә торган комплексы стадион, тренажер заллары, махсус җиһазланган йөгерү юллары, тир, һ.б. бар. Болар өстенә - Кара диңгезнең шифалы суы, тау һавасы, көньяк загары, биш тапкыр тәмле сыйлар – швед өстәле...

**Зәлия Баева:**

Чыннан да, Анапада үткән һәр көнебез истәлекләргә бай булды. Иртән гимнастика, тренировкалар, олимпия чемпионнары белән мастер-класслар була, аннары диңгездә су коенабыз, ярышлар уза. Кич белән төрле чараларда катнашабыз. “Интуиция” уены, квест формасында уеннар аеруча ошады. Бигрәк тә “Джаз-денс” кичләре хәтердә калды.

***Тәк-тәк, шушы урыннан тулырак итеп сөйләп китегез әле. Нәрсә ул джаз-денс?***

Джаз-денс – Көнбатыш Африка көйләре ритмына корылган, берничә стильне берләштергән заманча бию. Джаз-денс бию өчен махсус аяк киеме – джазовкалар кирәк. Мәсәлән, па-характериндагы катлаулы хәрәкәтләрне гадәти аяк киеме белән эшләп булмый. Бию ритмлы, интенсив музыкага башкарыла. Гәүдәне тою, дөрес тоту таләп ителә, чөнки сикерү, кискен борылу пластика, сыгылмалылык сорый. Спорт белән шөгыльләнүчеләр өчен бу бию бер дә катлаулы түгел. Аяктан егылганчы джаз-денс биегән кичләрне хәзер дә сагынам.

**Азат Хафизов:**

Килү белән, без яшьтәшләребез белән танышып, дуслашып беттек. Ярышка дип килсәк тә, монда бернинди дә көнчелек хисе юк. Конкурентлар күплеге җиңү дәртен сүндерә алмый. Спортның кайбер төрләрендә безнең команда өстен булса, башкаларында көндәшләр алга чыга. Без моны бөтенебез дә аңлыйбыз. Биредә дусларча атмосфера хакимлек итә. Берберенне аңлый белү көчле. Спорт характеры шулай формалаша торгандыр.

Танылган олимпия чемпионнары белән үткән мастер-класслар аеруча истә калды. Баскетбол уены серләре белән легендар Елена Баранова бүлеште. Самбо буенча дөнья чемпионы Марина Махнаткина ихтыяр көче тәрбияләү юлларын күрсәтте.



**Ильгина Хафизова:**

5 сентябрь көнне ярышларны ачу тантанасын үткәрделәр. Олимпия чемпионнары, күренекле спорт мастерлары, Рәсәйнең иң яхшы тренерлары “Президент уеннары” башлану белән котлап, уңышлы чыгыш ясавыбызны теләделәр. Бу минутларда Татарстан Республикасы һәм Мөслимебез данын яклауның никадәр җаваплы икәнен бөтен барлыгым белән тойдым.

21 сентябрь – Анапаны фашист илбасарларыннан азат иткән көн. Анапа 2011 нче елда “Сугышчан дан шәһәре” исеме алган икән. 23 сентябрь – Анапа шәһәре көне билгеләп үтелде. Безгә шушы матур чараларда катнашырга туры килде. Рәсәйнең бик күп төрле популяр артистлары, бию коллективлары чыгышын карадык. Мин беренче тапкыр мондый масштаблы бәйрәмне тамаша кылдым. Бүген дә шул тәэсирләр шаукымы астында йөрим.

# “ПРЕЗИДЕНТ ЯРЫШЛАРЫ” БӨТЕНРОССИЯ УЕННАРЫНДА

***Ләлә, сине урыннан сикерү буенча бронза медальгә ия булган кыз буларак беләбез. Мондый уңышның сере нәрсәдә? Бу – син теләгән күрсәткечме?***

**Ләлә Шәйхетдинова:**

Мин туганнан бирле спортзалда, бассейнда. Әтием физик тәрбия укытучысы булгач, бик бәләкәй чагымда ук мине чыныктыруга әһәмият бирә иде. Мөслимдә “Көзге кросс”та 5 яшьлек вакытта ук әти белән дистанцияне йөгереп үткәнем хәтердә. Истәлек булып “Иң яшь катнашучы” дигән Грамота саклана. Шуннан бирле җиңел атлетика белән туктаусыз шөгыльләнәм. Физик тәрбия буенча теорияне яхшы беләм, йөзү, сикерү, төрле дистанцияләргә йөгерү, төз ату, күтәрелү буенча күрсәткечләрем яхшы. ГТО буенча алтын медаль алдым. Ел саен физик тәрбия буенча олимпиадаларда катнашам, призлы урыннар алам.

Команда булгач, бөтен төрдә дә катнашырга туры килә. Баскетбол ярышларында Смоленск шәһәре кызлар командасы белән уйнап, 5:6 исәбе белән җиңү яуладык.



Урыннан ераклыкка сикерү буенча мондый дәрәҗәдәге ярышларда бронза медаленә ия булу, әлбәттә, зур уңыш. Ләкин минем холкым андый түгел: мин бервакытта да ирешелгәннәр белән канәгать була алмыйм. Бу миңа алга таба үз көчемне арттырырга стимул булды.

***Әмир Миннегалиев – “Футбол короле”. 40 команда арасында Мөслим гимназиясе егетләре командасының 2 нче урын алуы очраклымы? Мондый уңышка ирешүнең сере нәрсәдә?***

**Әмир Миннегалиев:**

Футболчының мәйданда иң төп коралы – техника булу. Техника булса, футболист ялгызы гына да берничә уенчыны “алдап”, тупны алып китә, көндәшенең капкасы янында ситуацияне контрольдә тота



ала, тупны тоткарлый белә. Мини-футбол, кагыйдә буенча, кечкенә мәйданчыкта уйнала, шуңа күрә тупның очу траекториясен дә, очу тизлеген дә исәпкә алырга, төгәл итеп үз уенчыңа тапшыра белергә, килгән тупны дөрес итеп кабул итә белергә кирәк. Уен хаталарны кичерми.

Безнең команданың уңышы нәрсәдә? Беренче чиратта, уен техникасының камил булуында. Икенчедән, уенчыларның бер-берсен аңлап уйнавында. Тренерлар моны “сыгранность” дип атыйлар. Уен барышында бик катлаулы моментлар булды. Бердәмлек аркасында, без җиңүгә ирештек.

***Ринат, син нинди ярышларда катнаштың? Көндәшләреңнең әзерлеге ничек иде?***

**Ринат Сафиуллин:**



Күп төрле ярышларны берләштергән спорт - многоборье дип атала. Бу ярыш берничә этаптан тора. Һәр төр ярышка баллар аерым куела, аннары гомуми зачет исәпләнә. Мин үземнең чыгышымнан бик канәгать. Рәсәйнең 86 төбәгеннән килгән спортчыларның күбесе күренекле спорт мастерлары кул астында шөгыльләнәләр. Гап-гади авыл мәктәбендә укуымны белгән дусларым арасында миңа шикләнеп караучылар да булды. 800 кеше арасында өченче урын – бу бик яхшы нәтиҗә, минемчә. Турникта тартылу, йөгерү, милли көрәш белән шөгыльләнү, системалы рәвештә үз өстемдә эшләү, максатка ирешүчән характерым миңа бу ярышларда ярдәм итте.

***Уку елы башында, без монда дәресләрдә интегеп утырганда, сез Кара диңгез буенда “бәрхет сезоны”нда рәхтләнеп ял итеп яттыгыз... Туган җирдән читтә якыннарыгыздан башка читен булмадымы?***

**Шамил Миннегалиев:**

Поезд тәрәзәсеннән Рәсәй белән танышып бардык. Төрле шәһәрләрне үттек. Поездан төшеп, чит җиргә аяк баскач, гаҗәпләнү, соклану хисе



биләп ала. Табигать гаҗәеп бай, матур. Күз күрмәгән агачлар, чәчәккә күмелеп утырган азалия, магнолия агачлары, җиләк-җимешнең күплегенә ис китә. Климат шәфкатьле, диңгездә коену искиткеч ләззәтле. Ярышлар белән мавыгып, сагынып, моңсуланып утырырга вакыт та булмады, телефоннан әти-әниләр белән хәбәрләшеп тордык. Шулай булса да, соңгы көннәрдә Мөслим турында күбрәк сөйләшә башладык. Экзотика шулкадәр тиз туйдыра, сагынганда мондагы матурлык күзгә күренми башлый икән. Мөслимебезне никадәр яратуыбызны читкә киткәч ныграк аңладык.

***Уеннар тәмамланды... Спортчыларыбыз исән-имин Мөслимебезгә – әти-әниләре, туганнары, дуслары янына, үзебезнең гимназиягә кайтып җиттеләр... Алда тагын яңа бурыч тора: спортта гына түгел, укуда да алдынгы булырга! “Без – мөслимлеләр!” шигарене туры калып, Рәсәй күләмендә районыбыз данын яңгыраткан егет-кызларга рәхмәт хисләрен җиткерәбез, укуда уңышлар, спортта яңа үрләр яулавын телибез.***

*“Анапист”лар белән Илүзә Кашапова аралашты*

# ҖӘЙГЕ ИСТӘЛЕКЛӘР

**Инзилә Тазова:**

Мин быел Миңгәр авылы сабантуенда катнаштым. Мондый масштабтагы сабантуй бәйрәмен беренче тапкыр күрәм. Билбау көрәшендә татар, башкорт, мари, удмурт, чуашлардан тыш Индия, Израиль, Франция вәкилләре, хәтта негрлар да бар иде. Елга аша салынган аркылы баганада капчык сугышы, шунда ук авыш баганага әтәчкә менү ярышы бик нык хәтердә калды. Аларны күпер өстеннән күзәтергә мөмкин. Бәйрәм төнге салют белән тәмамланды.

**Әдилә Бәдертдинова:**



Җәй – иң яраткан ел фасылым. Һәр елдагыча үзебезнең аланыбызга җиләккә бардык. Зурлар җиләкне чиләккә җыйдылар, ә мин игезәк энеләремне сыйладым. Алар, бер-берсе белән ярыша-ярыша, мин үзем биргән эре-эре җиләкләрне чуплап кенә торалар. Күрсәгез иде аларның ничек житез-житез ашаганнарын! Чиләккә җыючылар "без чиләкне тутырдык" дип мактанганда, без, апайларым белән, түп-түгәрәк эчләребезне сыпырып күрсәттек: янәсе, "без дә тутырдык".

Рәхәт көннәрең, матур истәлекләрең, урман-болыннардагы сый-нигъмәтләрең, күңелне сөендерә торган гүзәллегең өчен рәхмәт сиңа, җәй!

**Ранис Хәйретдинов:**

Мин җәйне Әмәкәй авылында – әбием белән бабам янында уздырдым. Алар, тылсымчы кебек, бөтен теләгебезне үтәп торалар. Үзебез дә тик ятмыйбыз: әбием белән бакчада чүп утысак, бабам белән чебиләргә читлек ясадык, кәтүгә чыктык.

Чаллыга сәяхәт аеруча истә калды. Яңа төрле каруселльләрдә баш әйләнгәнче уйнадык, "Профессияләр дөньясы" интерактив уенында үземне төрле һөнәр ияләре буларак сынадым.

**Адилә Нуруллина:**

Быелгы җәйдә гаиләбез белән Удмуртия башкаласы Ижауда булдык. Россиядәге иң зур зоопаркка бардык. Андагы җәнлекләр, кошлар, үсемлекләр дөньясының күп төрле булуы гаҗәпләндерде. Иж елгасында көймәдә йөрү, теплоходта сәяхәт матур истәлек булып хәтеремдә калды.

**Искәндәр Нуретдинов:**

Җәй башыннан ук яңгырлар башлангач, кәефем бөтенләй кырылган иде. Шулай да, җәй искиткеч файдалы үтте. Авылда ял итәргә дә, Әлмәт пляжында кызынырга да, футбол командасы составында Татарстан Республикасы буйлап ярышларда йөрергә дә житештем. Гимназиябезгә бик күп районнардан кунаклар килде. Кунакларны каршы алганда иң матур шигырь сөйләүче кем иде дип уйлыйсыз? Белмисезме? Ул – мин идем!

**Нияз Нургалиев:**

Җәйге ялларны без гаиләбез белән бергә үткәрәбез. Быел без Чаллыга дельфинарийга бардык. Дельфиннар искитмәле трюклар ясады, биеделәр, кыршау аша сикерделәр.

**Камилә Мингазова:**

Каникулда ял итеп кенә ятмадым: укытучыларның август киңәшмәсендә катнаштым. Миңа бик күп мәктәп директорлары, мәгариф идарәләре җитәкчеләре, укытучылар белән аралашырга, хәтта мәгариф министры Энгель Фаттахов алдында чыгыш ясарга туры килде.

Шундый көннәрнең берсендә Республиканың мәгариф идарәләре башлыклары алдында якташыбыз, балалар шагыйре М.Әхмәтҗановның "Туган тел" шигырен сөйләдем. Бу шигырьдә: "Әбиемнән күреп мин дә намаз укый башладым" - дигән юллар бар. Сөйләп бетергәч, Нурлат районы мәгариф бүлеге җитәкчесе: "Сеңлем, берәр дога укып бир әле," – дип мөрәҗәгать итте. Ике дә уйлап тормадым: әбием өйрәткән "Нәс" сүрәсен яттан укып күрсәттем. Җитәкче абый миңа хәер итеп 50 сум акча бирде.

**Ислам Хәсәнов:**

Җәйнең иң истәлекле көне – минем туган көнем. Без аны атна буе бәйрәм иттек. Туган көнгә Чаллыдан апайларым кайтты, бик күп бүләкләр бирделәр. Бергәләп Казан шәһәренә бардык. Ривьерада рәхәтләнеп ял иттек, Кремльдә, Кол Шәриф мәчетендә булдык, Бауман, Петербург урамнарында җәяүләп йөрдек.

**Илина Бариева:**



Быелгы җәйдә мин халыкара "Артек" лагеренда ял иттем. Монда баруны мин түземсезләнеп көттем. Алдан чемодан җыелды. Аэропортка баруым да беренче тапкыр. Әле мине самолетта да очу көтә! Дулкынлануымны белсәгез иде! Әти-әниләр, туган ягым белән хушлашу мизгелләре житте, самолетта урыннарыбызны алдык. 2 сәгать 20 минут сизелми дә үтеп китте. Ә күпме могҗиза көткәнне үзем дә аңлап бетерми идем. Лагерьга килеп керү белән, бөтенләй башка тормыш башланды. Самолетта ук дуслашып өлгергән дуслар белән хәзер дә аралашабыз. "Артек"та үткән көннәрне хәзер төш кебек кенә искә алам. Хыяллар чынга аша икән!

**Альбина Насыйфуллина :**

Сезнең "Урман иле" лагеренда ял иткәнегез бармы?. Әйдаманнар һәр көнебезне истәлекле, кызыклы итү өчен нәрсә генә уйлап тапмыйлар! Бер көнне без бөтен эшнең киресен башкардык. Бөтен нәрсә киресенчә булганга күрә, иң аз баллар җыйган "Купаты" төркеме җиңүче булды. Кичке аштан соң яңып торган дискәтүк оештырылды, хәлләребез бетеп егылганчы биедек. Тагын кайчан ямьле җәйләр житәр инде, тагын "Урман иле" лагерена барыр идем.

ТЫЛСЫМ+

Октябрь, 2017 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректорлар:** Шамукаева Эльвина
Солтанова Эльвина
**Корреспондентлар:** Салихова Динара
Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ

**Компьютерда җыючылар:**
Гилемов Азат
Шарифуллин Заһир
**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym